ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5 декабря 2019 г. № 6326

Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган
торак фонды тулай торакларында
торак урыннары бирү тәртибен
раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган торак фонды тулай торакларында торак урыннары бирү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2019 елның 05 декабрендәге
6326 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган
торак фонды тулай торакларында
торак урыннары бирү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәренең махсуслаштырылган торак фонды тулай торакларында торак урыннары бирү тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнгән.

2. Махсуслаштырылган торак фонды - гражданнарның аерым категорияләре яшәү өчен билгеләнгән муниципаль торак фондының торак урыннары җыелмасы. Торак урынын махсуслаштырылган торак урыны сыйфатында файдалану Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2006 елның 26 гыйнварында расланган 42 номерлы кагыйдәләрне үтәп, әлеге бинаны махсуслаштырылган торак фондына керткәннән соң гына рөхсәт ителә.

3. Тулай торакта торак урыннары муниципаль торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына карый.

.4. Тулай торактагы торак урыны читләштерелә, алмаштырыла, арендага, наемга бирелә алмый.

Глава 2. Тулай торакта торак урыны бирү

5. Тулай торакта торак урын Яр Чаллы шәһәрендә торак урыннары белән тәэмин ителмәгән гражданнарга бирелә һәм гражданнарның дәүләт хакимияте органында, җирле үзидарә органында, дәүләт яисә муниципаль унитар предприятиесендә, дәүләт яисә муниципаль учреждениесендә эшләү, хезмәт итү чорында вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән.

6. Тулай торакта мәйдан бер кешегә кимендә алты квадрат метр торак мәйданы хисабыннан чыгып бирелә, әмма Чаллы шәһәрендә куелган торак урыннар мәйданы бирү нормасыннан да артык түгел.

7. Тулай торакта торак урын алу хокукына ия граждан тулай торакта торак урын бирү турында гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итә.

8. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) хезмәткәр (граждан) хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган эш бирүченең тулай торакта торак урыны бирү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә юлламасы;

2) яшәү урыныннан белешмә;

3) гражданнарның гаилә әгъзаларына каравын раслаучы документларның күчермәләре;

4) эшкә кабул итү турында хезмәт килешүе күчермәсе;

5) паспорт күчермәләре, 14 яшькә кадәрге балалар – туу турында таныклык күчермәләре;

6) тулай торакта торак урыны бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданның Яр Чаллы шәһәре территориясендә торак урыны булмавын раслаучы документлар (1999 елның 31 декабренә кадәр).

9. Гражданнарның тулай торакта торак урыны бирү турында гаризалары кергән көннән башлап 30 календарь көн эчендә карала.

10. Тулай торакта торак урыны Башкарма комитет карары нигезендә бирелә.

3 бүлек. Тулай торактагы торак урынына найм килешүе

11. Башкарма комитетның гражданга тулай торакта торак урыны бирү турындагы карары тулай торактагы торак урынына найм килешүе төзү өчен нигез булып тора, ул әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча язма рәвештә төзелә.

12. Тулай торактагы торак урынына найм килешүе нигезендә, граждан тулай торактагы торак урынына урнаша. Тиешле килешү төземичә, граждан тулай торакка урнашырга яки тулай торактагы бер торак урыныннан башкасына күчәргә хокуклы түгел.

13. Тулай торактагы торак урынына найм килешүендә тулай торакта торак урыны бирелә торган граждан белән урнаша торган гаилә әгъзалары күрсәтелә. Граждан тулай торактагы торак урыннарына ир белән хатыннан, балигъ булмаган балалардан, шулай ук законнарда каралган очракларда башка затлардан тыш, башка гражданнарны гаилә әгъзалары буларак, урнаштырырга хокуклы түгел.

14. Тулай торакта торак урыны бирелгән граждан Россия Федерациясе Торак кодексы, тулай торактагы торак урынына найм килешүе белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак урыныннан файдаланган өчен түләү кертә.

15. Тулай торакта фактта биләгән торак урыныннан файдаланган өчен, гражданнарга күрсәтелә торган коммуналь һәм башка хезмәтләр өчен түләү Чаллы шәһәренең хокукый актларында билгеләнгән күләмдә алына.

16. Тулай торакта торак урыны бирелгән граждан:

1) торак бинаны билгеләнеше буенча һәм законнарда һәм муниципаль норматив хокукый актларда, шулай ук тулай торактагы торак урынына найм килешүендә билгеләнгән чикләрдә куллана;

2) тулай торактагы торак урынны техник яктан төзек һәм тиешле санитар хәлдә тота;

3) тулай торактагы торак урынны агымдагы ремонтлауны башкара;

4) тулай торактагы торак урыны, коммуналь һәм тулай торактагы торак урыны наймы килешүендә билгеләнгән башка хезмәтләр өчен түләүне үз вакытында кертә;

5) законнар һәм тулай торактагы торак урынына найм килешүе нигезендә башка хокукларга һәм бурычларга ия.

17. Тулай торакта найм килешүе нигезендә торак урыны бирелгән гражданның әлеге торак урынына билгеләнгән тәртиптә урнаштырылган гаилә әгъзалары әлеге торак урыныннан төзелгән килешү шартларында файдалану хокукы алалар.

18. Тулай торактагы торак урынына найм килешүе түбәндәге очракларда

өзелергә мөмкин:

1) якларның килешүе буенча теләсә кайсы вакытта;

2) тулай торакта торак урыны бирелгән гражданның гаризасы буенча теләсә кайсы вакытта;

3) тулай торакта торак урыны бирелгән граждан тарафыннан әлеге килешү буенча йөкләмәләр үтәлмәгәндә, шулай ук законнарда, тулай торактагы торак урынга найм килешүендә каралган башка очракларда суд тәртибендә.

19. Тулай торактагы торак урынына найм килешүе түбәндәге очракларда туктатыла:

1) хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәт тәмамланганнан соң;

2) законнарда, тулай торактагы торак урынга найм килешүендә каралган башка нигезләр буенча.

20. Тулай торактагы торак урынына найм килешүе өзелгән яки туктатылган очракта, гражданнар әлеге килешү нигезендә тулай торакта биләгән торак урыннарын өч көн эчендә бушатырга тиеш. Тулай торактагы торак урынын бушатудан баш тарткан очракта, әлеге гражданнар суд тәртибендә, башка торак урын бирелмичә, чыгарылырга тиеш.

21. Граждан тулай торактагы торак урыныннан башка даими яшәү урынына киткәндә, гаилә әгъзалары буларак кертелгән гражданнар әлеге урыннан файдалана алмый.

Башкарма комитет
Аппараты җитәкчесе Г.К. Әхмәтова